САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
422060, Республика Татарстан, Сабинский район,
п.г.т. Богатые Сабы, ул. Г.Закирова, 52

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ
422060, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Байлар Сабасы ш.т.п., Г.Закиров урамы, 52 йорт

тел. (84362) 2-31-33, 2-31-44, факс (84362) 2-31-74, e-mail: saba@tatar.ru, www.saby.tatarstan.ru

26.02.2015 № 294

№ _________ от ______________

# КАРАР

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Контроль-хисап палатасы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 38 статьясы, «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 05 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның 98 статьясы нигезендә Саба муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Контроль-хисап палатасы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2011 елның 22 декабрендәге 82 номерлы Саба муниципаль районы Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Контроль-хисап палатасы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

– 8 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 14 пункт өстәргә: «14) «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 05 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә сатып алулар өлкәсендә аудит башкару.

2. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының контроль-хисап палатасында:

– әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән контроль функцияләр уздыруның административ регламентын эшләргә һәм расларга;

– ел саен раслана торган тикшерүләр планы нигезендә контроль функцияләр үткәрүне тәэмин итәргә.

3. «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының контроль-хисап палатасы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2014 елның 23 маендагы 251 номерлы Саба муниципаль районы Советы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Саба муниципаль районының Контроль-хисап палатасы рәисенә Федераль салым хезмәтенең ТР буенча 10 нчы районара инспекциясендә Нигезләмәгә үзгәрешләр кертергә.

Саба муниципаль
районы Башлыгы Р.Н. Минниханов